ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ
ул. Карима Тинчурина, д. 29, г. Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР
БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
К. Тинчурин ур., 29 йорт, Казан шәһәре, 420021

Телефон: (843) 211-66-94, факс: (843)211-66-47, E-Mail: ojm@tatar.ru, сайт: http://ojm.tatarstan.ru

**Приказ** **г. Казань** **Боерык**

19.08.2020 г. № 247-од

Татарстан Республикасы биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 16.05.2018 ел, 124-од номерлы боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты тарафыннан бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Дәүләт хезмәтен күрсәтү эшен камилләштерү максаты белән боерам:

1. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 16 нчы маеннан 124-од номерлы «Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты тарафыннан бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты тарафыннан бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (2018 елның 14 ноябрендәге 344-од номерлы, 2019 елның 12 декабрендәге 387-од номерлы боерыклар белән кертелгән үзгәрешләрне күздә тотып) киләсе үзгәрешләрне кертергә:

1нче бүлектә:

1.3.5 кече пунктының икенче кызыл юлын «мәгълүмат стендларында» сүзләреннән соң «ТР Дәүләт комитетының рәсми сайтында,» сүзләрен өстәргә;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат

системасында, (реквизитларын һәм чыганакларын күрсәтеп) Комитетның рәсми сайтында урнаштырылган».»;

пункт 1.5:

бишенче кызыл юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең читтән торып эш урыны- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабреннән "Күп функцияле үзәкләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү эшчәнлегенең кагыйдәләрен раслау турында"гы 1376 нчы карары белән расланган , Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) шәһәр яки авыл җирлегендә төзелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офис)»;

җиденче кызыл юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба - гариза) астында дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос аңлашыла («Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 2 ст.1 п.). Гариза формасы әлеге Регламентның 1нче кушымтасында китерелгән.»;

2нче бүлектә:

2.1. пунктның «Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Аучылык һәм аучылык байлыкларын саклау һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба - 209-ФЗ номерлы Федераль закон) 21 статьясындагы 2, 9 пунктлары, Россия Табигать министрлыгының 2011 елның 20 гыйнварындагы 13 номерлы боерыгы белән расланган, Бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару тәртибе (алга таба - Тәртип)»;

2.2. пунктның «Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

15.12.2017 ел, 996 номерлы «Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган, Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәнең 4.1.43 пункты, Тәртип»;

2.6 пунктта:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына куела торган таләп атамасы» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшыра ала торган, норматив хокукый актлар нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге, ә шулай ук гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары,шул исәптән электрон рәвештә, аларны бирү тәртибе; документлар аларның карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма исеме»;

«Стандартка куелган таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1) Мөрәҗәгать итүченең алдан уйланган җинаять кылган өчен түләнмәгән яисә хөкем ителмәгән булуы (булмавы) турында белешмәләр – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына.
2) Мөрәҗәгать итүченең паспортының чынлыгын раслау турында белешмәләр (дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәткәндә) – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына.
Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе, әлеге Регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән.
Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:
дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда, аларны тапшыру яисә гамәлгә ашыру каралмаган гамәлләрне тормышка ашыру өчен документлар һәм мәгълүмат бирү;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә күрсәтелгән документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче дәүләт органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны, шул исәптән түләү кертүне раслаучы документны таләп итү;

№ 210-ФЗ Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны беренчел кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда аларның булмавы һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат бирү.»;

2.12. пунктның «Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указының 1 пункты»;

2.13. пунктның «Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесендә хезмәт күрсәтү стандартын раслау турында» 2018 елның 16 маендагы 371 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары»;

2.16. пунктның «Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«210-ФЗ номерлы Федераль закон; 2011 елның 6 апрелендәге «Электрон имза турында» 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба-63-ФЗ номерлы ФЗ)»;

3 нче бүлек:

3.4.1 пунктчасын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Комитет белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон формада запрослар формалаштыра һәм җибәрә:

«Хөкем ителгәнлек һәм (яки) җинаять эзәрлекләве факты булу (булмау) турында белешмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Административ регламентын раслау турында» Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының 2019 елның 27 сентябрендәге 660 номерлы боерыгы нигезендә, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына мөрәҗәгать итүченең алдан уйланган җинаять кылган өчен, түләнмәгән яисә хөкем ителүе өстеннән төшерелмәгән булу (булмау) турында белешмәләр бирү турында»;

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына мөрәҗәгать итүченең паспортының чынлыгын раслау турында белешмәләр бирү турында.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура, гаризаны теркәгәннән соң, бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына җибәрелгән запрослар.»;

3.4.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Мәгълүмат белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запрослар нигезендә соратып алына торган мәгълүматны тапшыралар.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар законда билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Комитетка җибәрелгән запросларга җавап бирү нәтиҗәсе булган белешмәләр (документлар), яисә баш тарту турында хәбәрнамәләр.»;

5 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлык, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе»;

Регламентка теркәлгән белешмә кушымтасында «Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Рәис | 211-66-47 | ojm@tatar.ru |
| Рәис урынбасары | 211-66-94 | Matveev.Yuriy@tatar.ru |
| Идарә башлыгы | 211-71-89 | Radik.Mutaharov@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Бүлек башлыгы | 211-71-89 | Dinar.Shakirov2@tatar.ru |
| Өлкән белгеч | 211-71-89 | Ismagilova.Natalya@tatar.ru |
| Өлкән белгеч | 211-71-89 | Almaz.Ismagilov@tatar.ru |

2. Рәис урынбасарларына, структур бүлекчәләр җитәкчеләренә, дәүләт хезмәте күрсәтүне турыдан-туры тәэмин итүче затларга Регламент нигезләмәләрен үтәүне һәм алар тарафыннан каралган документларны алып баруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип танырга.

Рәис Ф.С. Батков